| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
| **24.12.2018** | **№237** |

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 22 статьясы, «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнвары 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 11 июлендәге 563 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләре эшләре Министрлыгы мәсьәләләре турында» дип исемләнгән карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы Нигезләмәсе нигезендә, яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрне (шулай ук юридик затларны) кызыксындыру, мотивацияләү максатыннан б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының Мактау грамотасы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрының Рәхмәте

2. Беркетелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының Мактау грамотасы турында Нигезләмә;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрының Рәхмәте турында Нигезләмә;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләрен тапшыру Тәртибе.

3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының эш процессын оештыру секторына бүләкләү документларын кабул итү, бүләкләү өчен материаллар әзерләү, ведомство бүләкләрен рәсмиләштерү һәм тапшыру, аларның исәбен алып бару эшен оештырырга.

4. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә ел саен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы сметасында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләре бланкларын әзерләүне финанслау чыгымнарын күз алдында тотарга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының эшләр белән идарә итүчесе Э.М.Әхмәтгәреевка йөкләргә.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2018 елның 24 декабрендәге 237 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының
Мактау грамотасы турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының Мактау грамотасы (моннан соң – Мактау грамотасы, Министрлык) Министрлыкның ведомство бүләге булып тора.

2. Мактау грамотасы белән , Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәте стратегиясен үстерү, шул өлкә үсешенә зур өлеш керткән өчен , Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәтен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары хезмәткәрләре, шулай ук оешма, предприятие, учреждение, җәмәгать оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр бүләкләнә.

3. Мактау грамотасы белән шул өлкәдә 3 елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе булган һәм моңарчы Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәсәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарының Рәхмәтенә лаек булган хезмәткәрләр бүләкләнә.

4. Мактау грамотасы белән бүләкләү әлеге Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләрен тапшыру Тәртибе буенча тормышка ашырыла.

5. Мактау грамотасы тантаналы шартларда башкарыла.

Мактау грамотасының дубликаты кулга бирелми. Мактау грамотасы Министрлыкның дәүләт хезмәте, кадрлар белән эшләү һәм юридик эшләр секторы тарафыннан югалтылган очракта, Министрлыкның герблы мөһере белән расланган боерыктан өземтә (выписка) бирелә.

6. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән затларның исәбе министрлык тарафыннан алып бара.

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
2018 елның 24 декабрендәге 237
номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрының
Рәхмәте турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрының Рәхмәте (моннан соң –Рәхмәт) Министрлыкның ведомство бүләге булып тора.

2. Рәхмәт белән , Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәте стратегиясен үстерү, шул өлкә үсешенә зур өлеш керткән өчен , Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәтен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары хезмәткәрләре, шулай ук оешма, предприятие, учреждение, җәмәгать оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр бүләкләнә..

3. Рәхмәт белән бүләкләү әлеге Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләрен тапшыру Тәртибе буенча тормышка ашырыла.

4. Рәхмәт тантаналы шартларда башкарыла.

5. Рәхмәтнең дубликаты кулга бирелми. Рәхмәт кәгазе Министрлыкның дәүләт хезмәте, кадрлар белән эшләү һәм юридик эшләр секторы тарафыннан югалтылган очракта, Министрлыкның герблы мөһере белән расланган боерыктан өземтә (выписка) бирелә.

6. Рәхмәт белән бүләкләнгән затларның исәбе министрлык тарафыннан алып бара.

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
2018 елның 24 декабрендәге 237
номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының
ведомство бүләкләрен тапшыру
Тәртибе

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының (моннан соң – министрлык) ведомство бүләкләре бүләкләү формасы булып торалар һәм Министрлыкның боерыгы нигезендә эшләнәләләр.

2. Бүләкләү түбәндәге очракларда уздырыла:

еллык эшкә нәтиҗә ясаганда;

профессиональ бәйрәм, оешманың истәлекле һәм юбилей даталарын бәйрәм иткәндә.

Бүләкләү гражданнарның юбилей туган көннәренә (30 яшь, 40 яшь, 50 яшь һәм аннан соңгы һәр 10 ел), оешманың юбилей даталары (нигез салу, берләшү) (10 яшь, 20 яшь һәм аннан соңгы һәр 10 ел) бәйле уздырылырга мөмкин

3. Яшьләр көне (27 июнь) уңаеннан ведомство бүләкләрен тапшыру материаллары – Министрлыкка бәйрәмгә кадәр өч айдан да соңармыйча, ә юбилей, истәлекле даталарга бәйле бүләкләү күрсәтелгән датага ике айдан да соңармыйча тапшырылырга тиеш.

Бер кат Министрлыкгың ведомство бүләге белән бүләкләнгәннән соң киләсе бүләк 2 елдан да иртәрәк тапшырылмый.

4. Ведомство бүләкләрен тапшыру турындагы карарны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры (моннан соң – министр) тарафыннан Дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләү мәсьәләсен карый торгын Комиссия карары (йомгагы) нигезендә кабул ителә. Бүләкнең төре бүләкләүгә тәкъдим ителгән затның казанышлары дәрәҗәсе, характеры һәм бүләкләү турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

5. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында б\түбәндәге затлар ходатайство белдерә ала:

Министр урынбасары, Министрлык карамагындагы учреждениеләрнең җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләр башлыклары, гражданның төп эш урыныннан оешмалар ризалыгы буенча төбәкара яшьләр оешма, берләшмә һәм җәмгыять җитәкчеләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма орган җитәкчеләре, югары һәм урта уку йортлары җитәкчеләре.

6. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү мәсьәләсен карау өчен, әлеге Тәртипнеңң 5нче пунктында күрсәтелгән ходатайство бирергә хаклы булган һәр зат министр исеменә түбәндәге документларны тапшыра:

ходатайство;

1нче Кушымтада күрсәтелгән форма буенча бүләкләүгә тәкъдим ителгән затның конкрет казанышлары һәм уңышлары күрсәтелгән представление

7. Дисциплинар шелтә, федераль закон тарафыннан урнаштырылган кагыйдәләр буенча хөкемгә тартылулары булган затлар ведомство бүләкләре белән бүләкләнми.

8. Министрлык ведомство бүләкләре белән бүләкләү турындагы боерыкларының күчерелмәләре, шулай ук ведомство бүләкләре теге яки бу затны бүләкләүгә тәкъдим иткән оешманың ышанычнамәсе нигезендә бирелә.

9. Ведомство бүләгенә тәкъдим ителгән Министрлык хезмәткәренең хезмәт кенәгәсенә бүләкләү турында язма кертелә.

10. Ведомство бүләкләрен тапшыру министр яки аның кушуы буенча шул өлкә белән эшли торган министр урынбасары, яки оешманың (учреждение, берләшмәнең) башка вазыйфаи заты тарафыннан министр исеменнән тантаналы шартларда тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
ведомство бүләкләрен тапшыру
Тәртибенә беркетелгән
1нче Кушымта

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының
ведомство бүләкләрен тапшыруга
тәкъдим итү

1. Фамилия, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) ______________________________
2. Туган көне, ае, елы ________________________________________________________
3. Туган урыны ______________________________________________________________
4. Белеме _________________________________________________________________
(кайсы уку йортын һәм кайсы елда тәмамлады)
5. Фәнни дәрәҗәсе, фәнни исеме _________________________________________________
6. Тору урыны адресы ________________________________________________________
7. Нинди дәүләт, ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән
___________________________________________________________________________
8. Эш урыны, били торган вазыйфасы ___________________________________________
9. Гомуми хезмәт стажы
__________________________________________________________
10. Тармакта хезмәт стажы _______________________________________________________
11. Әлеге коллективта хезмәт стажы __________________________________________
12. Хезмәт эшчәнлеге (югары уку йортларында һәм махсус урта уку йортларында укуны, хәрби хезмәтне кертеп).

| Ай һәм ел | | Вазыйфа (оешманы күрсәтергә) | Оешма урнашкан урын |
|---|---|---|---|
| Кергән ел,ай, көн | Чыккан ел, ай, көн | | |
| | | | |
| | | | |

1-12 пунктлардагы белешмәләр хезмәт кенәгәсендәге мәгълүматларга туры килергә тиеш.

___________________________________________________________________________
___
М.У. (вазыйфа, имза, кадрлар хезмәте җитәкчесенең ФИОсы).

13. Бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның конкрет хезмәтләрен күрсәтеп характеристика:

___________________________________________________________

Кандидатура

_________________________________________________________________________

(Ф.И.О.)

хезмәткәрләр коллективы җыелышы яки аның советы тарафыннан тәкъдим ителә)

_________________________________________________________________________

(оешма исеме)

_________________________________________________________________________

(хезмәткәрнең коллективы, аның киңәшмәсе, коллегиясе датасы яки протокол номеры)

Оешма җитәкчесе Хезмәткәрләр коллективы җыелышы

яки аның киңәшмәсн рәисе

___________ ________________

(имза) (имза)

________________________ ___________________________

( (фамилия һәм инициаллар) (фамилия һәм инициаллар)

М.У. «__» ____________ ел М.У. «__»__________ел